РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» марта 2023 г. г. Альметьевск № 103

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында» 2015 елның 13 мартындагы 168 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында» 2015 елның 13 мартындагы 168 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 05 маендагы 77 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның «Әлмәт муниципаль районы Советының норматив хокукый актлары мониторингы» 5 бүлегендә:

1.1.1. 5.4 пунктның 5 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәис) еллык юлламасы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы законнарын үстерүнең теп юнәлешләре»;

1.1.2. 5.4 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Югары Суды».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов